КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 16

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Здравушка» тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен һәм «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Казан шәһәре» шәһәр округындагы Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Апрель» тернәкләндерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Шмидт урамы, 48 нче Б йорт адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Здравушка» тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – «Здравушка» тернәкләндерү үзәге) һәм 420139, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Рихард Зорге урамы, 121 нче йорт, 1210 нче бүлмә; 420039, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Восстание урамы, 46 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Казан шәһәре» шәһәр округындагы Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Апрель» тернәкләндерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – «Апрель» тернәкләндерү үзәге) үзгәртеп оештыру,

«Апрель» тернәкләндерү үзәгенең исемен һәм төп эшчәнлек максатларын калдырып, «Здравушка» тернәкләндерү үзәген «Апрель» тернәкләндерү үзәгенә кушу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Апрель» тернәкләндерү үзәге базасында өстәмә өч бүлек булдырырга:

58 урынга исәпләнгән иртә ярдәм күрсәтү бүлеге;

10 урынга исәпләнгән көндезге бүлек;

методик хезмәт бүлеге.

3. «Апрель» тернәкләндерү үзәген гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

эш көннәрендә исәпләнә торган 90 көн эчендә бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле булган, законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «Здравушка» тернәкләндерү үзәгенә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне алга таба файдалану турында тәкъдимнәр кертергә;

«Здравушка» тернәкләндерү үзәге эшчәнлеге туктатылу турындагы язу Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән датадан «Апрель» тернәкләндерү үзәге уставына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле чаралар аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру чараларын үткәрү чыгымнарын тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары өлешендә каралган акча чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, бу карарның 4 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән мөлкәт исемлеген алганнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә «Здравушка» тернәкләндерү үзәгенә элегрәк беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен «Апрель» тернәкләндерү үзәгенә тапшыруны тәэмин итәргә.

6. «Апрель» теркнәкләндерү үзәгенең дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү өлешендә каралган акча чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр

башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә бу карарның 4 пунктында каралган чаралар үтәлгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 21 сентябрь, 1026 нчы, «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карарларына тиешле үзгәрешләрне кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин